# КАРАР
# Татарстан Республикасы Азнакай район Советы

Азнакай шәһәре №335-45 12 март 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2015 елның 15 июнендәге 369-53 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлау нормативларын раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү хакында (13.12.2018 №221-32, 23.05.2019 №265-36, 20.08.2019 №283-38, 22.10.2019 №290-39, 12.12.2019 №303-41 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын үтәү йөзеннән, 2012 елның 10 июлендәге 117-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2015 елның 15 июнендәге 369-53 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлау нормативларын раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларына (13.12.2018 №221-32, 23.05.2019 №265-36, 20.08.2019 №283-38, 22.10.2019 №290-39, 12.12.2019 №303-41 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5.2 бүлектә:

а) 5.2.161 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ачык һәм ябык типтагы автостоянкалардан күрше объектларга кадәр ераклыкны Шәһәр төзелешенең СП 42.13330.2016 СНиП 2.07.01-89 таләпләренә туры китереп кабул итәргә кирәк. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру

һәм төзү  янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документларының  СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 исәпкә алып башкарылырга тиеш.»;

б) 5.207 пунктны  түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Автомобильләргә хезмәт күрсәтү объектларыннан күрше объектларга кадәр ераклыкны Шәһәр төзелешенең СП 42.13330.2016, СНиП 2.07.01.-89 таләпләренә туры китереп кабул итәргә кирәк. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү  янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документларының  СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 исәпкә алып башкарылырга тиеш.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

3.  Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай район Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин